УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**28.05.2013** г.Казань № 01-05/85- пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төр машиналарны һәм аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) теркәүгә алу, аларга дәүләт теркәвенә алу тамгалары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турында» 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карарлары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төр машиналарны һәм аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан тыш)

теркәүгә алу, аларга дәүләт теркәвенә алу тамгалары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналар һәм башка
төр техниканың техник торышына
күзәтчелек идарәсе боерыгы белән
расланды

# Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төр машиналарны һәм аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) теркәүгә алу, аларга дәүләт теркәвенә алу тамгалары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төр машиналарны һәм аларга тагылмаларны, аларга дәүләт теркәвенә алу тамгаларын бирү (Хәрби Көчләр һәм Россия Федерациясенең башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: юридик зат, шәхси эшкуар, физик зат, яисә аның исеменнән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итәргә вәкаләтле зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәтен үтәү Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе) һәм аның территориаль бүлекчәләре (алга таба – район һәм шәһәр бүлеге) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3.1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36 йорт, 101 кабинет.

1.3.2. Белешмә телефоннары, электрон почта адреслары турында мәгълүмат Регламентка карата 3 нче белешмәлек кушымтада китерелгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе телефоннары: 8 (843) 221-77-85, 221-77-89. Факс: 8 (843) 221-77-85.

Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла: http://gt№.tatarsta№.ru.

1.3.3. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең һәм район һәм шәһәрләрдәге бүлекләрнең эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм районнардагы

бүлекләрнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында http://gt№.tatarsta№.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм район бүлегенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм районнардагы бүлекләренә (электрон адреслары 3 нче белешмәлек кушымтада күрсәтелгән) язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 1995 елның 28 июнендәге карары белән расланган Үзйөрешле машина һәм техниканың башка төрләре паспорты турындагы нигезләмә (алга таба – Үзйөрешле машина һәм техниканың башка төрләре паспорты турындагы нигезләмә) («Российские вести» №154, 17.08.1995);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 16.01.1995 боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарны һәм аларга тагылмаларны дәүләт теркәве кагыйдәләре (алга таба – Машиналарны теркәү кагыйдәләре) («Российские вести» №81, 04.05.1995);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.);

Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче өлеш) 05.08.2000 №117-ФЗ (алга таба – РФ Салым кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 03.08.1998, 3824 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Үзйөрешле машиналар белән идарә итүгә кертү һәм тракторчы-машинист таныклыкларын бирү кагыйдәләрен раслау турында» 1999 елның 12 июлендәге 796 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 19.07.1999, №29, 3759 ст.) (алга таба – РФ Хөкүмәте карары №796);

Россия Федерациясе Министрлар Советы - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә (Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыентыгы, 20.12.1993, №51, 4943 ст.) (алга таба – Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 12.07.1999 №796 карары белән расланган

Үзйөрешле машиналар белән идарә итүгә һәм тракторчы-машинист таныклыкларын бирү кагыйдәләренә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы 19.07.1999, №29, 3759 ст) (алга таба – Үзйөрешле машиналар белән идарә итүгә һәм тракторчы-машинист таныклыкларын бирү кагыйдәләре);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 29.11.1999 №807 боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналар белән идарә итүгә рөхсәт бирү һәм тракторчы-машинист таныклыкларын бирү кагыйдәләрен куллану тәртибе турында инструкция («Российская газета» 22.02.2000, №37) (алга таба – Үзйөрешле машиналар белән идарә итүгә рөхсәт бирү һәм тракторчы-машинист таныклыкларын бирү кагыйдәләрен куллану турында инструкция);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, №46, 2144 статья);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турында нигезләмә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 03.02.2012, №9, 0321 ст.) (алга таба – Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе турында нигезләмә).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

машинаны теркәү - теркәү документлары һәм дәүләт теркәве билгесе бирелеп, машинаны яисә дәүләт исәбенә кую (теркәү журналында, автоматлаштырылган системада);

машинаны техник тикшерү (алга таба – техник карау) – машина, аның агрегатлары номерларын, шулай ук әлеге машинаның куркынычсыз эксплуатациясен тәэмин итә торган төеннәрнең эшкә сәләтле булу-булмавын тикшереп, машинаның техник торышын тикшерү;

машинага дәүләт техник каравын уздыру турында талон (эксплуатациягә кертү) – машинаның куркынычсыз эксплуатация таләпләренә туры килүен тикшерүне раслый торган документ.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләпләренең атамасы | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төр машиналарны һәм аларга тагылмаларны (алга таба - машина) теркәүгә алу һәм исәптән төшерү, аларга дәүләт теркәвенә алу тамгаларын бирү (Хәрби Көчләр һәм Россия Федерациясенең башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) | РФ Хөкүмәтенең 938 номерлы карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 460 номерлы карары;<br>РФдә үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә;<br>Үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспорты турында нигезләмә;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе турында нигезләмә;<br>Машиналарны теркәү кагыйдәләре |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе һәм районнардагы бүлекләре | ТР Министрлар Кабинеты карары №1064, 26.12.2011 |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төр машиналарны һәм аларга тагылмаларны (алга таба - машина) теркәүгә алу һәм исәптән төшерү, аларга дәүләт теркәвенә алу тамгаларын бирү (Хәрби Көчләр һәм Россия Федерациясенең башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 2.12 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте | Биш эш көне эчендә | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүнең срогы | | |
| 2.5. Закон яки башка төрле норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1. Гариза (1, 2 нче кушымталар).<br>2. Сату-алу шартнамәсе яки милекчелек хокукын раслый торган бүтән документ.<br>3. Сату турында боерык күчермәсе (юридик затлар өчен).<br>4. Кулланылышта булган машиналарны теркәгәндә ОС-1 формалы акт күчермәсе.<br>5. Исәптән төшерү турында тамгасы белән машинаны теркәү турында таныклык (элегрәк теркәлгән һәм исәптән төшерелгән машиналарны теркәгәндә).<br>6. Мөрәҗәгать итүченең паспорты (физик затлар һәм юридик затларның ышанычлы заты өчен).<br>7. Машина паспорты.<br>8. Йөк таможня декларацияләре (Россия Федерациясе территориясенә кертелгән машиналарга, номерлы агрегатларга, шул исәптән 6 айдан артык вакытка кертелгән)<br>9. Ата-аналарның (уллыкка алучыларның) яисә опека һәм попечительлек органнарының язма ризалыгы (аларның милекчеләре 18 яшькә җитмәгән затлар булган машиналарны теркәгәндә).<br>10. Хәрби часть тарафыннан бирелгән ирекле акт (коралланудан төшерелгән һәм хуҗалык максатларында файдалану өчен РФ Кораллы Көчләреннән тапшырылган машиналар өчен).<br>Документлар бер нөсхәдә тапшырыла | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 2 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган башка органнар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>2. Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>3. Салым түләүченең идентификация номеры турында мәгълүмат.<br>4. Дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр һәм/яки Дәүләт техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү турында белешмәләр (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе,). | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм | Килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Чистартылган яисә өстәп язылган, сүзләре сызылган яисә сөйләшенмәгән төзәтүләре булган, шулай ук карандаш белән тутырылган документлар. | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 1.13 пп. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Техник тикшерү, номерларны чагыштыру өчен машинаны күрсәтмәү.<br>2. Машинаның яки аның агрегатларының фактик номерларының документлардагы номерларга туры килмәве.<br>3. Башка милекчегә теркәлгән булуы.<br>4. Урланган машиналар исемлегендә булуы.<br>5. Юридик әһәмиятле гамәлләрне башкару өчен чикләнештә булган (арест, тыю, конкурс эше).<br>6. Дәүләт пошлинасы өчен түләү булмавы | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 2.8, 2.21, 2.22 пунктлары |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре. | 1. Яңа тракторны, үзйөрешле машинаны паспорт бирмичә теркәү:<br>дәүләт пошлинасы:<br>дәүләт теркәве билгесен биреп - 1000 сум.<br>теркәлү турында таныклык биреп - 300 сум.<br>техник тикшерү узу турында талон биреп - 300 сум. | 333.33 статья РФ Салым кодексы; |

| | | |
|---|---|---|
| | паспортка үзгәрешләр кертү - 200 сум.<br>2. Элек исәпкә алынган тракторны, үзйөрешле машинаны яисә тагылманы теркәү:<br>дәүләт пошлинасы:<br>дәүләт теркәве билгесен биреп - 1000 сум.<br>үзйөрешле машина паспорты бирелгән очракта - 500 сум.<br>техник тикшерү узу турында талон биреп - 300 сум.<br>машинаны теркәү турында таныклык биреп - 300 сум.<br>паспортка үзгәрешләр кертү - 200 сум.<br>3. Үзйөрешле машиналар паспортын бирмичә элек исәптә торучы тракторларны, үзйөрешле машиналарны теркәү: дәүләт пошлинасы: - 1800 сум.<br>4. Элек теркәлгән тракторларны, үзйөрешле машиналарны алар булган урыннарда вакытлыча теркәү: дәүләт пошлинасы - 200 сум.<br>5. Үзйөрешле машинаның элек бирелгән паспортына үзгәрешләр кертү: дәүләт пошлинасы - 200 сум.<br>6. Бушаган номер агрегатына таныклык бирелгәндә: дәүләт пошлинасы - 200 сум.<br>1. Яңа тракторны, үзйөрешле машинаны паспорт бирмичә теркәү:<br>теркәлә торган машиналарның санына карап, техник торышын тикшермичә, номерларны кушып, тракторны, үзйөрешле машинаны яисә тагылманы карау: | |

| | | |
|---|---|---|
| | 1 берәмлек - 185 сум.<br>2 берәмлек - 104 сум.<br>3 берәмлек - 77 сум.<br>4 берәмлек - 64 сум.<br>5 һәм аннан күбрәк берәмлек - 56 сум.<br>2. Элек исәпкә алынган тракторны, үзйөрешле машинаны яисә тагылманы теркәү:<br>теркәлә торган машиналарның санына карап, техник торышын тикшермичә, тракторны, үзйөрешле машинаны яисә тагылманы карау номерларны чагыштырып:<br>1 берәмлек - 209 сум.<br>2 берәмлек - 128 сум.<br>3 берәмлек - 101 сум.<br>4 берәмлек - 87 сум.<br>5 һәм аннан күбрәк берәмлек - 80 сум.<br>3. Үзйөрешле машиналар паспортын бирмичә элек исәптә торучы тракторларны, үзйөрешле машиналарны теркәү:<br>теркәлә торган машиналарның санына карап, техник торышын тикшермичә, номерларны кушып, тракторны, үзйөрешле машинаны яисә тагылманы карау:<br>1 берәмлек - 209 сум.<br>2 берәмлек - 128 сум.<br>3 берәмлек - 101 сум.<br>4 берәмлек - 87 сум.<br>5 һәм аннан күбрәк берәмлек - 80 сум.<br>4. Дәүләт теркәве билгесе һәм ПСМ бирмичә элек исәптә торучы тракторларны, үзйөрешле | |

| | | |
|---|---|---|
| | машиналарны теркәү:<br>теркәлә торган машиналарның санына карап, техник торышын тикшермичә, номерларны кушып, тракторны, үзйөрешле машинаны яисә тагылманы карау:<br>1 берәмлек - 209 сум.<br>2 берәмлек - 128 сум.<br>3 берәмлек - 101 сум.<br>4 берәмлек - 87 сум.<br>5 һәм аннан күбрәк берәмлек - 80 сум.<br>5. Бушаган номер агрегатына таныклык бирелгән очракта:<br>агрегатлар санына карап тикшерү өчен:<br>1 берәмлек - 185 сум.<br>2 берәмлек - 104 сум.<br>3 берәмлек - 77 сум.<br>4 берәмлек - 64 сум.<br>5 һәм аннан күбрәк берәмлек - 56 сум. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры | Биргән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Катнашу урыны түбәндәгеләр белән җиһазландырылган:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br><br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>мәгълүмат стенды, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель белән | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>әлеге Регламентны дәүләт хезмәткәрләре | |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан бозуларга карата прецендентлар (нигезле шикаятьләр) булу (прецендентларның, шикаятьләрнең Идарәнең, район һәм шәһәр бүлекләренеңдәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми исәбенә карата нисбәте);<br>Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:<br>район һәм шәһәр бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматлар булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен Интернет челтәре аша мәгълүмат ресурслары ярдәмендә алу мөмкинлеге | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештә гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен тапшыру юлы белән, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге бар | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) тапшырылган документларны тикшерү;

3) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

4) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә һәм/яки район һәм шәһәр бүлекләренә гариза тапшыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм/яисә район һәм шәһәр бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүче шәхсән кәгазьдә яисә электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша район һәм шәһәр бүлегенә тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш машиналарын һәм аларга тагылма машиналарын теркәү, аларда дәүләт теркәү тамгалары бирү (бирүдән баш тарту) турында гариза бирә, әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар беркетә. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә әтәргеч булган рәсми мөрәҗәгатьне тапшыру мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

3.4. Райгоротэшнең баш дәүләт инженеры-инспекторы (алга таба - Инспектор) түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны терки, документларны кабул итә.

документларны әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе предметына тикшерә.

теркәлә торган машинаны тикшерү турында карар кабул итә.

Документлар әлеге регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә хокук бозуларны бетерү өчен документлар кайтарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗә: тикшерелгән документлар, теркәлә торган машинаны карау турында карар кабул ителгән яки хокук бозуларны бетерү өчен мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.

3.5. Инспектор ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр бирү турында, – Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры турында мәгълүмат;

дәүләт пошлинасын түләү турында һәм/яки Дәүләт техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү турында белешмәләр бирү турында – Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсеннән;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: район һәм шәһәр бүлегенә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.6. Кергән мәгълүматлардан соң, мөрәҗәгать итүче һәм Инспектор тарафыннан машинаны яисә тагылманы карау өчен дата, урын һәм вакыт килештерелә:

машинаны яки номерларны тикшергән прицепны карау һәм техник торышны таләпләр нигезендә тикшерү (әгәр машина яңа булмаса һәм кулланyда булса);

техник торышны тикшермичә (әгәр машина яңа булса) номерларны чагыштырып, машинаны карау;

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар мөрәҗәгать итүченең урынын, вакытын һәм аны узып китү датасын инспектор белән килештерелгән көнендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таләпләр нигезендә машинаны яисә номерларны тикшереп карау һәм техник торышы тикшергән тагылманы карау.

3.7. Барлык күрсәткечләр туры килгән очракта, 3.6 пунктында үткәрелгән чаралардан соң инспектор тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарны һәм аларга тагылмаларны теркәү, аларга дәүләт теркәү тамгаларын бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гарызнамәләргә җаваплар

килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗә: тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарны һәм аларга тагылмаларны теркәү (теркәүдән баш тарту) турында, аларда дәүләт теркәү тамгаларын бирү (бирүдән баш тарту) турында карар.

3.8. Инспектор тарафыннан түбәндәгеләр башкарыла:

машина яисә тагылма турында белешмәләрне автоматлаштырылган исәпкә алу системасына кертү;

машинаның паспортын, теркәү турында таныклыкны чыгартып алу;

машина хуҗасына кул куйдыртып дәүләт теркәвенә алу тамгасын, машинаны һәм тагылманы теркәү турында таныклыкны, машина һәм тагылма паспортын бирү.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар теркәлү турында карар кабул ителгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү билгесенә бирелгән таныклык, машинаны, тагылманы теркәү турында таныклык, машина, тагылма паспорты.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүенә.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы һәм район һәм шәһәр бүлеге җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшереп тору Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы тарафыннан башкарыла.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешенә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм

оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук әлеге Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауны) һәм карарларга югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять белдерү юлы белән дә гамәлгә ашырыла.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук андагы вазыйфаи затларның, дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе һәм район һәм шәһәр бүлеге хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять белдерү хокукына ия.

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы кабул иткән карарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән язу һәм басма хаталарын төзәтүдән баш тарткан

очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтыннан (http://www.gt№.tatarsta№.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яшәгән урыны турында белешмәләр яисә аталышы, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятьләр аны тапшыручы дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән

чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы гариза бирүчегә язмача яисә, аның ихтыяры белән, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Административ регламентка
1 нче кушымта

Дәүләт техник күзәтчелек
бүлеге башлыгына
________________________________
________________________________
территориаль бүлек исеме,
район, шәһәр күрсәтелә

Баш дәүләт инженер-инспекторга
________________________________
________________________________
Инженер-инспекторның Ф.И.А.

**ГАРИЗА**

Мин ______________________________________________________________________
(Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, ата исеме)
паспорт сериясе________ №_________________ бирелгән _________________________
_____________ бирелү датасы _______________ яши торган адрес:__________________
элемтә телефоны ______________________________________________________________
Сездән үтенәм: ___________________________________________________________
(теркәргә)
Гаризага терким (төп нөсхәләре):
1. Үзйөрешле машинаның паспорты, сериясе, номеры _____________________________
бирелгән ____________________________ бирү датасы ____________________________
2. Шартнамә _______________________________________ №______ __________________
(сату-алу, лизинг, китертү һ.б.)
шартнамәнең икенче ягы _________________________________________________________
(сатучы, лизингка бирүче һ.б.)
3. Кабул итү-тапшыру акты №____________ ______________________________________
4. Үзйөрешле машинаны (тагылманы) теркәүгә алу турында таныклык
код ______________ серия, номер ____________ бирелде _____________________________
5. Йөк таможня декларациясе (мөһер белән таныкланган күчермәсе) __________________
6. Ярашлылык сертификаты (мөһер белән таныкланган күчермәсе) ____________________
Машина турында белешмәләр:
_______________________________________________________________________________

Атамасы________________________________________________________________________
Марка ______________________ Чыгарылган ел _______________________________
Завод № (рама) ________________________________________________________________
Двигатель № ______________________ кВт/ат.к. _________________________________
Тапшыру тартмасы № _________________________ Мост №_________________________
Төсе _________________________ Дәүл. терк. тамг. _________________________________

«___»__________ 201__ ел. __________________________ ______________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имзасы)

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы тикшерә торган белешмәләр һәм документларның төп нөсхәләре:

1. Гражданин паспорты.
2. ИНН №______________________________________________________________
3. Дәүләт пошлинасын түләү, квитанция №__________ датасы ___________ суммасы (сум) ________
4. Дәүләт техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү, квитанция №_______ датасы ________ суммасы (сум) _______
5. ОСАГО полисы, сериясе, номеры _________________ кем тарафыннан бирелгән ______________________
(әгәр хәрәкәт итүнең максималь тизлеге 20 км/сәг артыграк булса)
________________________________________бирү датасы __________________________
Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы
____________________________________________________________________________
«___»___________ 201__ ел. М.У. (имза) (тулы имза)
Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе баш дәүләт инженер-инспекторы бәяләмәсе:
_____________________________________________________________________________
(теркәргә, дәүләт теркәү билгесен бирергә)
Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы
______________ ______________________________________________________________
«___»___________ 201__ ел. М.У. (имза) (тулы имза)
Бирелде:
_____________________________________________________________________________

1. Дәүләт теркәвенә алу билгесе, тибы______________________, коды ________,
номеры _______.
2. Үзйөрешле машинаның паспорты, сериясе ______________, номеры________
3. Теркәү турында таныклык: сериясе _________, номеры ____________;
4. Дәүләт теркәвенә алу билгесе, тибы__________, коды ________,
номер _______.
5. Бушаган номер агрегатына таныклык:
____________________________, сериясе __________, номеры ________________.
(агрегатның исеме)
____________________________, сериясе __________, номеры ________________.
(агрегатның исеме)
____________________________, сериясе __________, номеры ________________.
(агрегатның исеме)
Алу турында тамга:
»___»__________ 201__ ел. ___________________ _________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имзасы)
_________________________________________________________________

Административ регламентка
2 нче кушымта

Дәүләт техник күзәтчелек бүлеге башлыгына
___________________________________
территориаль бүлек исеме, район, шәһәр күрсәтелә
Баш дәүләт инженер-инспекторга
___________________________________
___________________________________
Инженер-инспекторның Ф.И.А.

**ГАРИЗА**

______________________________________________________________________
(оешманың атамасы)
_____________________________________ тел.: ________________________
(оешманың юридик адресы)
_________________________________________________________ йөзендә
(оешма җитәкчесе, фамилиясе, исеме, ата исеме)
Сездән сорый _____________________________________________________
(теркәргә)
Гаризага терким (төп нөсхәләре):
1. Үзйөрешле машинаның паспорты, сериясе, номеры _____________________
бирелгән ___________________________ бирү датасы ______________________
2. Шартнамә _______________________________________ №______ __________
(сату-алу, лизинг, китерү һ.б.)
шартнамәнең икенче ягы ___________________________________________
(сатучы, лизингка бирүче һ.б.)
3. Кабул итү-тапшыру акты №____________ _______________________________
4. Үзйөрешле машинаны (тагылманы) теркәүгә алу турында таныклык
код ______________ серия, номер ____________ бирелде ______________________
5. Йөк таможня декларациясе (мөһер белән таныкланган күчермәсе) ___________
6. Ярашлылык сертификаты (мөһер белән таныкланган күчермәсе) ___________
7. Ышанычнамә ____________________________________________________
8. Боерык ________________________________________________________
(төшерү турында, югалту һәм җәзага тарту турында һ.б.)
Машина турында белешмәләр:
______________________________________________________________________

Атамасы_______________________________________________________________
Марка ______________________ Чыгарылган ел _____________________________
Завод № (рама) _________________________________________________________
Двигатель № ______________________ кВт/ат.к. ______________________________
Тапшыру тартмасы № _________________________ Мост №___________________________
Төсе _________________________ Дәүл. терк. тамг. ___________________________
______________________________________________________________________

Оешма җитәкчесе _________________ _________________________
М.У. (имза) (тулы имза)

Баш бухгалтер _______________ ___________________________________

«___»___________ 201__ ел. (имза) (тулы имза)

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы тикшерә торган белешмәләр һәм документларның төп нөсхәләре:

1. Ышанычлы затның паспорты.

2. ОГРН _______________ ИНН ________________ КПП _____________________________

3. Дәүләт пошлинасын түләү, квитанция №__________ датасы ___________ суммасы (сум)_________

4. Дәүләт техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү, квитанция №_______ датасы ________ суммасы (сум) _______

5. ОСАГО полисы, сериясе, номеры _________________ кем тарафыннан бирелгән ______________________

(әгәр хәрәкәт итүнең максималь тизлеге 20 км/сәг артыграк булса)

________________________________________бирү датасы ________________

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең
баш дәүләт инженер-инспекторы

_____________ __________________________

«___»___________ 201__ ел. М.У. (имза) (тулы имза)

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе баш дәүләт инженер-инспекторы бәяләмәсе:

_____________________________________________________________

(теркәргә, дәүләт теркәү билгесен бирергә)

Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы

_____________ __________________________

«___»___________ 201__ ел. М.У. (имза) (тулы имза)

Бирелде:

_________________________________________________________________________

1. Дәүләт теркәвенә алу билгесе, тибы__________, коды ________,
номер _______.

2. Үзйөрешле машинаның паспорты, сериясе ______________, номеры________

3. Теркәү турында таныклык: серия _________, номеры _____________;

4. Дәүләт теркәвенә алу билгесе, тибы__________, коды _________,
номер _______.

5. Бушаган номер агрегатына таныклык:

_____________________________, сериясе __________, номеры ________________.
(агрегатның исеме)

_____________________________, сериясе __________, номеры ________________.
(агрегатның исеме)

_____________________________, сериясе __________, номеры________________.
(агрегатның исеме)

Алу турында тамга:

»___»__________ 201__ ел. ___________________ ____________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имзасы)

_______________________________________________________________

Административ регламентка
3 нче (белешмәлек) кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең
район һәм шәһәр бүлекләре

| Район | Код | Телефон | Индекс | Адрес |
|---|---|---|---|---|
| Әгерҗе | 885551 | 2-20-43 | 422230 | Әгерҗе ш., Гагарин ур., 70 й. |
| Азнакай | 885592 | 7-02-76 | 423330 | Азнакай шәһәре, Нефтьчеләр урамы, 23А |
| Аксубай | 884344 | 2-89-18 | 423060 | Аксубай штп., Совет урамы, 11а, |
| Актаныш | 885552 | 3-13-16 | 423740 | Актаныш ав., Ленин проспекты ур., 7 |
| Алексеевск | 884341 | 2-62-74 | 422900 | Алексеевск штп, Чистай урамы, 6 й. |
| Әлки | 884346 | 2-16-68 | 422870 | Базарлы Матак ав., Солнечная ур., 1 й. |
| Әлмәт | 88553 | 37-47-87 | 423450 | Әлмәт ш., Агрохимсервис бинасы |
| Апас | 884376 | 2-13-53 | 422350 | Апас ав., Гагарин ур., 11 |
| Арча | 884366 | 3-22-66 | 422000 | Арча штп, Совет мәйданы, 12 й. |
| Әтнә | 884369 | 2-10-43 | 422750 | Олы Әтнә ав., Совет ур., 38 |
| Баулы | 885569 | 5-41-85 | 423930 | Баулы шәһәре, Сәнәгать зонасы, Анико бинасы, а/я 50 |
| Балтач | 884368 | 2-52-33 | 422250 | Балтач ш.т.п., Ленин урамы, 42 |
| Бөгелмә | 885594 | 4-14-46 | 423230 | Бөгелмә шәһәре, Я. Гашек, 3 й. |
| Буа | 884374 | 3-15-97 | 422400 | Буа ш., Космовский ур., 33 й. |
| Югары Ослан | 884379 | 2-14-26 | 422570 | Югары Ослан ав., Чехов ур., 18 й. |
| Биектау | 884365 | 3-08-48 | 422700 | Биектау т/ю ст. п., Школьная ур., 17 й. |
| Чүпрәле | 884375 | 2-23-79 | 422470 | Иске Чүпрәле ав., Дзержинский ур., 2 |
| Алабуга | 885557 | 7-86-78 | 423604 | Алабуга шәһәре, Беренче май урамы, 50 |
| Зәй | 885558 | 7-08-15 | 423520 | Зәй шәһәре, Крупская урамы, 6, |
| Яшел Үзән | 884371 | 5-77-88 | 422540 | Яшел Үзән ш., Ленин ур., 38 й. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Кайбыч | 884370 | 2-11-15 | 422330 | Олы Кайбыч авылы, Гыйсмәтуллин урамы, 3 |
| Кама Тамагы | 884377 | 2-19-09 | 422820 | Кама Тамагы штп, К. Маркс ур., 2 |
| Кукмара | 884364 | 2-74-86 | 422110 | Кукмара ш., Ленин ур., 28 й. |
| Лаеш | 884378 | 2-81-80 | 422610 | Лаеш штп., Чернышевский ур., 32 |
| Лениногорск | 885595 | 5-02-44 | 423250 | Лениногорск ш., Гончаров ур., 1 й. |
| Мамадыш | 885563 | 3-34-16 | 422192 | Мамадыш ш., Совет ур., 26 й. |
| Менделеевск | 885549 | 2-50-04 | 423650 | Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. |
| Минзәлә | 885555 | 3-27-92 | 423700 | Минзәлә ш., К. Маркс ур., 77 |
| Мөслим | 885556 | 2-59-96 | 423970 | Мөслим авылы, Пушкин урамы, 43а |
| Түбән Кама | 88555 | 47-32-28 | 423550 | Түбән Кама ш., Кораб ур., 40 й. |
| Яңа Чишмә | 884348 | 2-21-37 | 423190 | Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 |
| Нурлат | 884345 | 2-06-93 | 423040 | Нурлат шәһәре, Совет урамы, 117 |
| Питрәч | 884367 | 3-06-59 | 422770 | Питрәч ав., Совет ур., 20 й. |
| Балык Бистәсе | 884361 | 2-34-97 | 422650 | Балык Бистәсе ав., Ленин ур., 48а |
| Саба | 884362 | 2-32-66 | 422060 | Байлар Сабасы ав., Г. Закиров ур., 52. |
| Сарман | 885559 | 2-50-57 | 423362 | Сарман ав., Куйбышев ур., 36 й. |
| Спас | 884347 | 3-03-83 | 422840 | Болгар шәһәре, Широнов урамы, 17 й. |
| Тәтеш | 884373 | 2-55-60 | 422370 | Тәтеш ш., Свердлов ур., 61 й. |
| Тукай | 88552 | 70-02-44 | 423800 | Чаллы шәһәре,<br>М. Җәлил проспекты, 46 |
| Теләче | 884360 | 2-13-19 | 422080 | Теләче ав., Ленин ур., 40. |
| Чирмешән | 884396 | 2-24-36 | 423100 | Чирмешән ав., Техническая ур., 36 й. |
| Чистай | 884342 | 5-25-60 | 422980 | Чистай ш., К. Маркс ур., 61 |
| Ютазы | 885593 | 2-73-13 | 423950 | Урыссу ш.т.п., Пушкин урамы, 38 й. |
| Казан | 8843 | 273-54-50 | 420073 | Казан шәһәре, Спорт урамы, 33 |

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе

| Адресы | Вазыйфа | Телефон | Сайт | Электрон адрес |
|---|---|---|---|---|
| 420111, ТР, Казан ш., Федосеев ур., 36 й. | Идарә җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш дәүләт инженер-инспекторы – Зыятдинов Радик Рәгыйп улы | 2217785 | http://gt№.tatarsta№.ru | gt№.rt@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адресы | Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Сайт | Электрон адрес |
|---|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 | Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы | (843) 2647746 | www.prav.tatarsta№.ru | pisma@tatar.ru |

Электрон документ формасында дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алу өчен электрон адреслар

| Район һәм шәһәр бүлеге | Электрон почта адресы |
|---|---|
| Әгерҗе | Gosteh№adzor.Agryz@tatar.ru |
| Азнакай | Gosteh№adzor.Az№akae@tatar.ru |
| Аксубай | Gosteh№adzor.Aksubae@tatar.ru |
| Актаныш | Gosteh№adzor.Akta№ys@tatar.ru |
| Алексеевск | Gosteh№adzor.Aleksee@tatar.ru |
| Әлки | Gosteh№adzor.Alkeevs@tatar.ru |
| Әлмәт | Gosteh№adzor.Almet@tatar.ru |
| Апас | Gosteh№adzor.Apas@tatar.ru |

| | |
|---|---|
| Арча | Gosteh№adzor.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә | Gosteh№adzor.At№ya@tatar.ru |
| Баулы | Gosteh№adzor.Bavly@tatar.ru |
| Балтач | Gosteh№adzor.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә | Gosteh№adzor.Bugulma@tatar.ru |
| Буа | Gosteh№adzor.Bui№sk@tatar.ru |
| Югары Ослан | Gosteh№adzor.Uslo№@tatar.ru |
| Биектау | Gosteh№adzor.Vysok@tatar.ru |
| Чүпрәле | Gosteh№adzor.Drozh@tatar.ru |
| Алабуга | Gosteh№adzor.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй | Gosteh№adzor.Zai№sk@tatar.ru |
| Яшел Үзән | Gosteh№adzor.Zele№@tatar.ru |
| Кайбыч | Gosteh№adzor.Kaybici@tatar.ru |
| Кама Тамагы | Gosteh№adzor.K_Uste@tatar.ru |
| Кукмара | Gosteh№adzor.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш | Gosteh№adzor.Laishev@tatar.ru |
| Лениногорск | Gosteh№adzor.Le№i№og@tatar.ru |
| Мамадыш | Gosteh№adzor.Mamadys@tatar.ru |
| Менделеевск | Gosteh№adzor.Me№del@tatar.ru |
| Минзәлә | Gosteh№adzor.Me№zel@tatar.ru |
| Мөслим | Gosteh№adzor.Muslyum@tatar.ru |
| Түбән Кама | Gosteh№adzor.№izh№ek@tatar.ru |
| Яңа Чишмә | Gosteh№adzor.№ovohehmi№sk@tatar.ru |
| Нурлат | Gosteh№adzor.№urlat@tatar.ru |
| Питрәч | Gosteh№adzor.Pestrec@tatar.ru |
| Балык Бистәсе | Gosteh№adzor.Sloboda@tatar.ru |
| Саба | Gosteh№adzor.saba@tatar.ru |
| Сарман | Gosteh№adzor.Sarma№@tatar.ru |

| | |
|---|---|
| Спас | Gosteh№adzor.Spasski@tatar.ru |
| Тәтеш | Gosteh№adzor.Tetyush@tatar.ru |
| Тукай | Gosteh№adzor.Tykai@tatar.ru |
| Теләче | Gosteh№adzor.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән | Gosteh№adzor.Cherem@tatar.ru |
| Чистай | Gosteh№adzor.Chist@tatar.ru |
| Ютазы | Gosteh№adzor.Yutaza@tatar.ru |
| Казан | Gosteh№adzor.Kaza№@tatar.ru |